Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башлыгы

КАРАРЫ

2020 елның 13 ноябре, № 4

**«Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Югары Казаклар авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.2020 елның 27 ноябрендә 11 сәгать 00 минутта Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге Югары Казаклар авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенын билгеләргә. Югары Казаклар авылы, 1 Май урам, 23 нче йорт адресы буенча урнашкан мәчет бинасында гражданнар җыены үткәрергә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары , 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Югары Казаклар авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән, 2021 елда үзара салымны 2000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

-юлларда чокырларны ямау, вак таш җәю һәм асфальт җәю, смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелек;

- янгын гидрантларын,җиңсәләрен,колонкаларын,стволларны сатып алу һәм урнаштыру; смета документларын төзү ;

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Олыяз авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Олыяз авыл җирлеге башлыгы: Р.Ф.Маликов